ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2019 Казан шәһәре № 3-23/э

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә сату өстәмәләре билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аналогларны чагыштыру ысулын кулланып гарантияле тәэминатчыларның сату өстәмәләрен исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2017 елның 21 ноябрендәге 1554/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр, әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән сату өстәмәләре билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2019 № 3-23/э карарына кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән сату өстәмәләре (тарифлар НДС башка күрсәтелә)

сум/кВт·сәг

| т/с | Татарстан Республикасында гарантияле рәвештә җиткерүченең аталышы | Сату өстәмәсе | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кулланучыларның «халык» тариф төркеме һәм кулланучыларның аңа тиңләштерелгән категорияләре | | кулланучыларның «электр энергиясен электр энергиясе югалтуларны компенсацияләү өчен сатып алучы челтәр оешмалары» тариф төркеме | | башка кулланучылар – үзләренә караган энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге 670 кВт ким булганлыкка карап, төркемчә буенча | | башка кулланучылар – 670 кВт башлап 10 МВт кадәр энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге күләменә карап, төркемчә буенча | | башка кулланучылар – үзләренә караган энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге кимендә 10 МВт булуына карап, төркемчә буенча | |
| | | I яртыеллык | II яртыеллык | I яртыеллык | II яртыеллык | I яртыеллык | II яртыеллык | I яртыеллык | II яртыеллык | I яртыеллык | II яртыеллык |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте | 0,3628 | 0,4259 | 0,0827 | 0,0852 | 0,1557 | 0,2514 | 0,0568 | 0,0838 | 0,0519 | 0,0838 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге